ГЛАВА
Русско-Ошнякского
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
РЫБНО-СЛОБОДСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

422642, с. Русский Ошняк,
ул. Школьная, дом 7а

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛЫК БИСТӘСЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
РУС ӘШНӘКГЕАВЫЛ
ЖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

422642, Рус Әшнәге,
Мәктәп урамы, 9а йорт

Тел.: (84361) 24643, факс: (84361) 24643, эл.адрес: Rosn.Rs@tatar.ru, сайт: ribnaya-sloboda.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

09 ноябрь 2022 ел Рус Әшнәге ав № 7

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Рус Әшнәге торак пунктында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы "Рус Әшнәге авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясы нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Рус Әшнәге авыл җирлегенең Рус Әшнәге авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының беренче этабын 2022 елның 23 ноябрендә 10 сәгать 00 минутка билгеләргә.

2. Халык җыенын үткәрү өчен торак пунктта яшәүчеләр исемлеген территориаль билге буенча бүләргә.

3. Халык җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләне расларга:

Сез 2022 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Рус Әшнәге авыл җирлегенең Рус Әшнәге авыл торак пунктында тору урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешесеннән (уку йортларына йөреп укучы студентлардан гайре) һәм мобилизацияләнгән гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 500 сум күләмендә үзара салым акчасы кертүгә һәм тупланган средстволарны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп түбәндәге эшләрне башкару өчен тотуга ризамы:

- су белән тәэмин итү системаларын, су кудыру башняларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистарту һәм Рус Әшнәге

авылында яшәүчеләргә су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын ремонтлау;

- авыл чикләрендә (Рус Әшнәге авылында) җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау;

- Рус Әшнәге авылы урамнарын төзекләндерү өчен вак таш сатып алу;

- Рус Әшнәге авылы урамнарын төзекләндерү өчен вак таш китертү өчен транспорт хезмәтләре өчен түләү;

- Рус Әшнәге авылы урамнарының юл йөрү өлешен кышкы чорда карап тоту (урамнарны чистарту);

- урамнарны яктыртуны җайга салу;

- Рус Әшнәге авылы урамнарының читләреннән чүп үләннәре чабу;

"ӘЙЕ" "КАРШЫ"

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Рус Әшнәге авыл җирлегенең түбәндәге адресы буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендында: Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Рус Әшнәге авылы, Мәктәп урамы, 9а йорт,Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге "Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы"нда кабул ителү белән 3 көн эчендә урнаштырырга.

6. Әлеге карар аның басылып чыккан (халыкка җиткерелгән) көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Рус Әшнәге авыл җирлеге
Башлыгы В.Х.Хаҗиев